РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.07.2020 № 899-п

Техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының
һәм иминлегенең конструктив һәм башка
характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән
объектларның проект документациясе таләпләренә
туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле
техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында
биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру
буенча комиссия төзү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” Саба муниципаль район Советының 2015 елның 10 сентябрендәге 319 номерлы карары нигезендә, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру буенча комиссия төзергә.

2. Техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру буенча комиссия составын расларга (кушымта итеп бирелә).

3. Техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру буенча комиссия турындагы Нигезләмәне расларга. (кушымта итеп бирелә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы И.Б. Таиповка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М. Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 7 июлендәге 899-п номерлы карары белән РАСЛАНГАН

**Техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Ишниязов М.Р. | Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Галиуллин А.М. | Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, комиссия рәисе урынбасары; |
| Рамазанов Э.Д. | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы урынбасары, комиссия секретаре; |
| Комиссия әгъзалары | |
| Галимуллин А. Р. | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсенең Саба һәм Теләче муниципаль районнары буенча районара күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге начальнигы, эчке хезмәт подполковнигы (килешү буенча); |
| Фатыйхов Р. С. | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарында территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Закиров И. Г. | “Татарстан Республикасы буенча Федераль янгынга каршы хезмәтнең 129 янгын бүлеге” Саба янгын сүндерү һәм коткару гарнизоны башлыгы, эчке хезмәт подполковнигы (килешү буенча); |
| Сөнгәтуллин Р. Р. | “Татарстан Республикасының техник инвентаризацияләү бюросы” АҖ Саба бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Авыл җирлекләре башлыклары | Күчемсез милек объектының урнашу урыны буенча |

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның 7
июлендәге 899-п номерлы
карары белән РАСЛАНГАН

**Техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру буенча комиссия турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

**1.1.** Техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру буенча комиссия турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” Саба муниципаль район Советының 2015 елның 10 сентябрендәге 319 номерлы карары нигезендә эшләнгән.

**1.2.** Нигезләмә техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру буенча комиссиянең эшен регламентлаштыра. (алга таба текст буенча – Комиссия).

**1.3.** Әлеге Нигезләмә, мондый биналарны, корылмаларны эксплуатацияләгәндә федераль законнар нигезендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш, биналарга, корылмаларга тикшерү уздырылганда кулланыла.

**1.4.** Комиссия Саба муниципаль район Советының 2015 елның 10 сентябрендәге 319 номерлы карары белән расланган техник регламентларның

объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә тикшерү үткәрә.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары.

**2.1**. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

– техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатларында биналарны, корылмаларны тикшерү буенча эшләр башкару;

## 3. Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары

**3.1.** Үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

– Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тиешле мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

– Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча дәүләт контроль (күзәтчелек) органнары, физик һәм юридик затлар вәкилләрен үз утырышларында тыңларга;

– Комиссия утырышына эшчәнлекләре өлкәсенә биналарның һәм корылмаларның техник торышын билгеләү белән бәйле мәсьәләләр кергән кызыксынучы якларны, өстәмә экспертларны, төрле оешма һәм учреждениеләр вәкилләрен чакыртырга;

– Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча Башкарма комитет Җитәкчесе каравына тәкъдимнәр кертергә.

## 4. Комиссиянең эш тәртибе

**4.1.** Комиссия составына рәис, рәис урынбасарлары, сәркатип, комиссия әгъзалары керә.

**4.2.** Комиссия составына Саба муниципаль районы Башкарма комитеты вәкилләре дә кертелә. Комиссия рәисе итеп Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе билгеләнә.

**4.3.** Комиссия составына шулай ук санитар-эпидемиологик, янгын, экология һәм башка куркынычсызлык, куллланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә (алга таба – дәүләт күзәтчелеге (контроль) органнары) дәүләт контролен һәм күзәтчелеген үткәрүгә, шәһәр һәм авыл җирлекләрендә, башка муниципаль берәмлекләрдә булган күчемсез милек объектларын инвентаризацияләү һәм теркәү үткәрүгә вәкаләтле органнар вәкилләре, шулай ук кирәк булган очракта-архитектура, шәһәр төзелеше органнары һәм тиешле оешмалар вәкилләре, билгеләнгән тәртиптә проект

документларына һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза бәяләмәләрен әзерләү хокукына аттестацияләнгән экспертлар кертелә.

Комиссия тәкъдимнәр бирү өчен техник экспертларны, оешма вәкилләрен, проектлаучы оешмаларны һәм башка белгечләрне җәлеп итәргә хокуклы.

**4.4.** Биналарны, корылмаларны тикшерү өчен махсус белемнәр кирәк булса, аны үткәрү өчен комиссия тарафыннан экспертлар, эксперт һәм башка оешмалар һәм (яки) дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары вәкилләре җәлеп ителә.

**4.5.** Комиссия утырышлары биналарны, корылмаларны эксплуатацияләүгә карата Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозу, биналарда, корылмаларда авария хәлләре барлыкка килү яки биналар, корылмалар җимерелү куркынычы барлыкка килү турында физик яки юридик затлардан гаризалар кергән очракта үткәрелә.

**4.6.** Мөрәҗәгать итүчегә һәм бина, корылма милекчесенә яки бина, корылмага ия булган затка, закон нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан, биналарга, корылмаларга тикшерү уздырылган көнгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, тапшыру турында белдерүе булган заказлы почта юлламасы белән, яки тикшерүне уздыруда катнашу өчен физик яки юридик зат гаризасында күрсәтелгән башка ысул белән биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру турында хәбәр ителә.

**4.7.** Биналарда, корылмаларда авария очраклары барлыкка килү яисә биналарның, корылмаларның җимерелү куркынычы барлыкка килү турында гариза килгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә һәм бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы затка, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан, муниципаль хокукый акт басылып чыккан мизгелдән, биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру турында мөмкин булган теләсә нинди ысул белән хәбәр ителә.

**4.8.** Биналарны, корылмаларны тикшергәндә түбәндәгеләр үткәрелә:

– төзелеш конструкцияләренең төзеклеген (заманча техник диагностика чараларын кулланып), инженер-техник тәэмин итү системаларын, инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен һәм аларның элементларын тикшерү;

– үткәрелгән тикшерүләр, контроль тикшерү һәм (яки) бина, корылмалар нигезләренә, төзелеш конструкцияләренә, инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә һәм инженерлык-техник тәэмин итү системаларына, аларның элементларына мониторинг үткәрү даталары һәм нәтиҗәләре турында, бинага, корылмага техник хезмәт күрсәтү буенча башкарылган эшләр, бинага, корылмага агымдагы ремонт үткәрү турында, бинаны, корылманы эксплуатацияләү барышында ачыкланган бозуларны бетерү турында башкарма хакимият органнары тарафыннан бирелгән күрсәтмәләрнең даталары һәм эчтәлеге турында, әлеге бозуларны бетерү турында белешмәләр кертелгән бинадан, корылмадан файдалану журналын тикшерү;

– күпфатирлы йортны тикшергән очракта, күпфатирлы йортны эксплуатацияләү буенча инструкцияне дә кертеп, күпфатирлы йортка техник документ белән танышу;

– техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләренә туры китереп бина, корылманың техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү өчен кирәк булган башка чаралар.

**4.9**. Биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру срогы гаризаны теркәгән көннән алып 20 көннән дә артык булмаска, ә биналарда, корылмаларда авария очраклары барлыкка килү яисә биналарны, корылмаларның җимерелү куркынычы барлыкка килү турында гариза килгән очракта - гариза теркәлгән вакыттан 24 сәгатьтән дә артык булмаска тиеш.

**4.10.** Биналарны, корылмаларны тикшерү комиссия тарафыннан бина, корылманың урнашу урыны буенча үткәрелә.

**4.11.** Биналарны, корылмаларны тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия секретаре тарафыннан бинаны, корылманы тикшерү турында бәяләмә төзелә.

Бинаны, корылманы тикшерү турындагы нәтиҗәгә тикшерелүче бинаны, корылманы техник диагностикалау материаллары һәм бинаны, корылманы тикшерү барышында рәсмиләштерелгән башка материаллар (нигезләмәгә кушымта) куела.

**1.1.** Бәяләмә барлык документлар белән бергә Саба муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырылырга тиеш.

**1.2.** Биналарга, корылмаларга тикшерү уздырганда, техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләре бозылу очраклары ачыкланган очракта, биналарны, корылмаларны тикшерү турындагы бәяләмәдә ачыкланган хокук бозуларны бетерү чаралары турында тәкъдимнәр бәян ителә.

**1.3.** Биналарны, корылмаларны тикшерү турындагы бәяләмәнең күчермәсе гариза бирүчегә, бинаны, корылманы эксплуатацияләүгә җаваплы затка, аны раслаганнан соң өч көн эчендә җибәрелә яисә күрсәтелгән затларга имза өчен тапшырыла, ә биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру, биналарда, корылмаларда авария хәлләре барлыкка килү яки бина, корылмаларның җимерелү куркынычы туу турындагы гариза нигезендә башкарылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә, бинаны, корылманы эксплуатацияләү өчен җаваплы затка, биналар, корылмаларга тикшерү уздыру көнендә тапшырыла.

**1.4.** Техник регламентларның объектлар ышанычлылыгының һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикалары таләпләре, күрсәтелгән объектларның проект документациясе таләпләре бозылу очраклары ачыкланган очракта, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты биналарны, корылмаларны тикшерү турындагы бәяләмәнең күчермәсен, ул расланганнан соң өч көн эчендә, вәкаләтенә әлеге бозуны кылган затны җаваплылыкка тарту мәсьәләсен хәл итү эше кергән органга, вазыйфаи затка җибәрә.

**1.5.** Биналарга, корылмаларга тикшерү уздыру турында белешмәләр Саба муниципаль районы Башкарма комитеты комиссиясе секретаре тарафыннан алып барыла торган биналарга, корылмаларга тикшерү уздыруны исәпкә алу журналына кертелә.

**1.6**. Биналарны, корылмаларны эксплуатацияләгәндә федераль законнар нигезендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырылса, биналарга, корылмаларга тикшерү үткәрелми.

Бу очракта биналарны, корылмаларны эксплуатацияләүгә карата Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозу, биналарда, корылмаларда авария хәлләре барлыкка килү яки биналарның, корылмаларның җимерелү куркынычы барлыкка килү турында гариза, федераль законнар нигезендә биналарны, корылмаларны эксплуатацияләгәндә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органга, теркәлгән көннән җиде көн эчендә җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүчегә комиссия секретаре тарафыннан биналарга, корылмаларга тикшерү уздырудан баш тарту турында һәм федераль законнар нигезендә биналарны, корылмаларны эксплуатацияләгәндә дәүләт контролен (күзәтчелеген)гамәлгә ашыручы органга, гариза теркәгәннән соң җиде көн эчендә, гариза юллау турында язма хәбәр җибәрелә.